# КАРАР

**17 ноябрь, 2020 ел** **№10**

**Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Мәчкәрә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 16 хәм 17 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Мәчкәрә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

-Мәчкәрә авылы М. Җәлил урамы юлларына вак таш җәю;

-Мәчкәрә авылы Октябрь урамы буенча вак таш җәелгән юлларны чокырларны ямау; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- скважина өчен насос алу;

- янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру;

- видеокүзәтү системасын урнаштыру;

-Мәчкәрә авылында юлларны кардан чистарту; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Мәчкәрә авылы зиратларын карап тоту, сатып алу һәм койма урнаштыру; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 160 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 102 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 102 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Мәчкәрә авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Мәчкәрә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Мәчкәрә авылы М. Җәлил урамы юлларына вак таш җәю;
- Мәчкәрә авылы Октябрь урамы буенча вак таш җәелгән юлларны чокырларны ямау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- скважина өчен насос алу;
- янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру;
- видеокүзәтү системасын урнаштыру;
- Мәчкәрә авылында юлларны кардан чистарту; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Мәчкәрә авылы зиратларын карап тоту, сатып алу һәм койма урнаштыру; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип таныргa.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Күкшел авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хәмидуллин